КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 9 июнь г.Казань № 703

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 29 март, 194 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы», «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре эшчеләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 29 март, 194 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 7 август, 660 нчы; 2020 ел, 27 август, 748 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1189 нчы; 2022 ел, 22 август, 880 нче; 2022 ел, 15 сентябрь, 1005 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемендә «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулада «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы» һәм «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» дәүләт бюджет учреждениеләре җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен исәпләп чыгарганда кулланыла торган тапкырлау коэффициентлары исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен исәпләп чыгарганда кулланыла торган тапкырлау коэффициентлары».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин